**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 02 2026 ел № 22

**Әтнә муниципаль районының**
**2025 елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2026 елга бурычлар**

Әтнә муниципаль районы башлыгы Р.Ш. Хисамиевның 2025 елда Әтнә муниципаль районының социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2026 елга бурычлары турындагы хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Әтнә район Советы Әтнә муниципаль районы башлыгының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүен билгеләп үтә. Хисап чорында муниципаль районның җирле үзидарә органнары икътисадны һәм социаль өлкәне тотрыклы үстерүгә, районның барлык тормыш тәэмин итү системаларының тотрыклы эшләвенә һәм район халкының лаеклы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итүгә, милләтара, конфессияара һәм гражданнар татулыгын ныгытуга, җирле үзидарәне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән эзлекле сәясәт алып бардылар.

Әтнә муниципаль районының алга таба нәтиҗәле социаль-икътисадый үсеше, 2026 елга бурычларны уңышлы тормышка ашыру максатларында Әтнә район Советы карар кабул итте:

1. Әтнә муниципаль районының 2025 елгы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2026 елга бурычлары турындагы хисапны игътибарга алырга.
2. Әтнә муниципаль районы депутатларына үз округларындагы сайлаучыларга Әтнә муниципаль районы башлыгының 2025 елда Әтнә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2026 елга бурычлары турындагы хисабын җиткерергә тиеш.

3. Әтнә районы башкарма комитетына:

- район башлыгы докладында һәм гражданнар җыеннарында әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гамәлгә ашыру буенча эш планын төзергә һәм расларга, төп бурычларның үтәлешен тәэмин итәргә.

4. Барлык милек формасындагы оешма житәкчеләренә:

- халыкка күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын арттыру буенча максатчан эш алып барырга;
- энергия ресурсларын экономлы рәвештә куллануны игътибарга алырга, чыгымнарны оптимальләштерергә;
- хезмәткәрләрнең хезмәт хакы үсешен тәэмин итәргә;
- куркынычсыз хезмәт шартларын, җитештерелә торган продукциянең сыйфатын, хезмәт җитештерүчәнлеген булдырырга.

5. Авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләренә:

- үсеш шартларын тагын да камилләштерергә;
- җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына аеруча игтибар итәргә;
- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нәтиҗәле итеп файдалану өчен чаралар күрергә.

6. Җирле үзидарә органнары җирлекләре җитәкчеләренә:

- җирлекләрнең вәкиллекле органнары утырышларында Әтнә муниципаль районы башлыгының 2025 елда Әтнә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2026 елга бурычлары турындагы хисабын тикшерергә һәм докладта әйтелгән кисәтүләрдән һәм тәкъдимнәрдән чыгып, чаралар планын эшләргә;
- территорияне комплекслы социаль-икътисадый үстерүне дәвам итәргә;
- яшьләрне авылда калдыру өчен кредитлау һәм торак төзелеше программаларыннан актив файдаланырга;
- халыкның тормыш дәрәҗәсе кимүгә юл куймау һәм барлык гражданнарның социаль хезмәтләрдән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен чаралар күрергә;
- авылларны төзекләндерү, яшелләндерү, торак пунктларның санитар чисталыгын саклау, экологик иминлекне тәэмин итү чараларын дәвам итәргә;
- авылда өстәмә эш урыннары булдыру буенча чаралар күрергә.

7. Әтнә муниципаль район финанс-бюджет палатасына:

- бюджет оешмаларындагы даими финанс чыгымнарын,бигрәк тә,су,ут,газ, җылылык белән тәэмин итүдәге чыгымнарны нәтиҗәле файдаланырга;
- Районның берләштерелгән бюджетын төгәл үтәргә, бюджет законнары белән туры килүен тәэмин итәргә;
- Барлык милек формасындагы оешмалардан,шәхси затлардан район бюджетына һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм түләүләрне үз вакытында кертүне тәэмин итәргә.

8. Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына жирне, муниципаль миллекне нәтиҗәле файдалануны даими рәвештә контрольдә тотырга, максатчан булмаган файдалануга юл куймаска.

9. Әтнә муниципаль район хисап палатасына муниципаль миллеккә карата максатчан булмаган финанс чыгымнарын булдырмау максатыннан контрольне көчәйтергә.

10. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетына, авыл җирлекләре башлыкларына, депутатлар корпусына һәм районның барлык активына:

- МХОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары һәм һәлак булган хәрбиләрнең гаилә әгъзалары проблемаларын хәл итүдә ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә;
- мемориаль комплексларны һәм сугыш ветераннарын күмү урыннарын даими рәвештә тиешле хәлдә тотарга.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль район башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш. Хисамиев